ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

*БУА РАЙОН СОВЕТЫ*

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

*БУИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ*

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

19 ноябрь 2013ел № 10-36

**Буа район Советының 2006 елның 28 декабрендәге 102-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына үзгәрешләр кертү турында**

Буа муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеген камилләштерү һәм тапшырылган вәкаләтләрне нәтиҗәле үтәү максатларында Буа район Советы «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында» 2008 елның 22 ноябрендәге 114-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Буа район Советының 2006 елның 28 декабрендәге 102-3 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына (2007 елның 07 сентябрендәге 10-18 номерлы Буа район Советы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Вәкиллекле орган аппаратының, башкарма комитет аппаратының, муниципаль районның башка җирле үзидарә органы аппаратының мөстәкыйль бүлеге башлыгы урынбасары» вазыйфасы атамасыннан соң 3 бүлектә «Муниципаль районның җирле үзидарә органы җитәкчесе ярдәмчесе», «Муниципаль районның башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе» вазыйфасын өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына кертелгән күп тапкырлар үзгәрешләргә бәйле рәвештә Буа муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

3. «Буа муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрын раслау турында» 2006 елның 28 декабрендәге 102-13 номерлы, «Буа муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 07 сентябрендәге 10-18 номерлы, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары муниципаль вазыйфалары реестрына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 25 декабрендәге 8-23 номерлы карарларын үз көчләрен югалткан дип санарга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа район Советы аппараты җитәкчесе (Пенкин С.А.) өстенә йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа муниципаль районы Советы рәисе А.К. Айзетуллов

Кушымта

**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры**

**1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары**

Муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе;
муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;
муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;
муниципаль районның башка җирле үзидарә органы җитәкчесе;
муниципаль районның башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары;
муниципаль район башкарма комитетының эшләр идарәчесе.

**2. Муниципаль хезмәтнең баш муниципаль вазыйфалары**

Муниципаль районның башкарма комитеты, җирле үзидарәнең башка органы бүлеге башлыгы;
вәкиллекле орган аппараты, башкарма комитет аппараты, муниципаль районның җирле үзидарә органы аппараты бүлеге башлыгы.

**3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы муниципаль вазыйфалары**

Муниципаль район башкарма комитетының бүлек башлыгы урынбасары;
вәкиллекле орган аппаратының, башкарма комитет аппаратының, муниципаль районның башка җирле үзидарә органы аппаратының мөстәкыйль бүлеге башлыгы урынбасары;
муниципаль районның җирле үзидарә органы җитәкчесенең ярдәмчесе;
муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесенең ярдәмчесе.

**4. Муниципаль хезмәтнең өлкән муниципаль вазыйфалары**

Муниципаль район башкарма комитеты бүлегенең баш белгече;
муниципаль район башкарма комитеты аппараты, вәкиллекле орган аппараты бүлеге баш белгече;
муниципаль районның башка җирле үзидарә органы башкарма комитеты бүлегенең әйдәүче белгече;
вәкиллекле орган аппараты, башкарма комитет аппараты, башкарма комитет аппараты, муниципаль районның башка җирле үзидарә органы аппараты бүлегенең әйдәүче белгече;
җирле үзидарәнең башка органы бүлегенең әйдәүче белгече.

**5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары**

Муниципаль районның башкарма комитеты, җирле үзидарәнең башка органы бүлегенең 1 категорияле белгече;
вәкиллекле орган аппараты бүлеге, башкарма комитет аппараты, муниципаль районның башка җирле үзидарә органы аппараты 1 категорияле белгече.